ПРОЕКТ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2026 елның «___» маеннан № ____

2026 елның II кварталына гомуми торак мәйданының
бер квадрат метрының бәясен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре белән тәэмин итү дәүләт программасын раслау турында» 2019 елның 03 октябрендәге 888 номерлы карары нигезендә, 2026 елның I яртыеллыгына торак урыннарының бер квартир метры бәясенең уртача күрсәткечен билгеләү буенча «Татарстан Республикасы бәяләүчеләр союзы» коммерциячел булмаган партнерлыгының эксперт-консультация советы тикшеренүләре нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының 2025 елның 08 декабрендәге 273 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак – коммуналь хуҗалык хезмәтләре күрсәтү белән тәэмин итү» дәүләт программасының «2026 – 2030 елларга Татарстан РеспубликасыЯңа Чишмә муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» программасын гамәлгә ашыру кысаларында, авыл җирендә яшәүче яшь гаиләләрнең торак шартларын федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты исәбенә яхшырту чараларын үткәрүгә социаль түләүләр күләмен исәпләү өчен Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә 2026 елның II кварталына торакның гомуми мәйданының бер квадрат метры бәясе 56 827 сум 00 тиен күләмендә дип расларга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда: https://pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында: https://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Бутина Анна Ивановнага йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фасахов